СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ БОЕРЫК

2025 елның 28 апреле Алабуга шәһәре № 424

Алабуга муниципаль районы Советының «Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы каршындагы үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 31 маендагы 346 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, Татарстан Республикасының «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы каршындагы үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләренең һәм белгечләренең һөнәри эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында, Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Алабуга муниципаль районы Советының «Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы каршындагы үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 31 маендагы 346 номерлы карары нигезендә, 2025 елның 1 маеннан Алабуга муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы каршындагы үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләренең һәм белгечләренең бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган айлык вазифаи окладлары күләмнәрен арттырырга һәм түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.3 пунктындагы 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Алабуга муниципаль районының Финанс - бюджет палатасы каршындагы үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең вазифаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазифасы | Алабуга муниципаль районы Финанс-бюджет палатасының структур бүлекчәсе - үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
|---|---|
| | Төп оклад, сумнарда |
| Структур бүлекчә җитәкчесе - баш хисапчы | 39 800 |
| Җитәкче урынбасары | 36 480 |
| Бүлек башлыгы | 33 500 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 30 800 |
| Әйдәп баручы хисапчы, әйдәп баручы икътисадчы | 29 500 |
| Хисапчы, икътисадчы | 27 800 |

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэм ин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнован иеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны икътисади үсеш, бюджет, салымнар, тариф сәясәте, эшкуарлыкка ярдәм итү мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Комиссия рәисе урынбасары Г.П. Баганов